# *Яшьлегем эзләре*

*Мансур Шиһапов* сүзләре




та яшь - ле - гем хис - лә - рен, шо - мырт - лар ак шә - лен я - бын -
са, са - гы - нам а - вы - лым кич - лә - рен. Са - гы -
нам, ө - зе - леп са - гы - нам ял - кын -
лы яшь - ле - гем эз - лә - рен.

Җил белән серләшкән каеннар
Яңарта яшьлегем хисләрен,
Шомыртлар ак шәлен ябынса,
Сагынам авылым кичләрен.
Сагынам, өзелеп сагынам
Ялкынлы яшьлегем эзләрен.

Назлы җил, салмак җил китерә
Чәчәкле болынның исләрен.
Мин тоям, мин тоям җилләрнең
Яшьлектән наз булып искәнен.
Сагынам, өзелеп сагынам
Шул назлы яшьлегем эзләрен.

Бирелеп хыялга, уйларга
Тыңлыйм мин агышын чишмәнең,
Чишмәләр җырлыйлар җыр итеп,
Җырлыйлар яшьлегем хисләрен.
Саклаган, саклаган авылым,
Давыллы яшьлегем эзләрен.